# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

Яңа Әхмәт авыл җирлегендә 2024 елда
гражданнарга үзара салым кертү турында

19 октябрь 2023 ел № 1

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы 2022 елның 24 ноябре № 1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт авылында халык җыены

**карары:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Сарман авыл җирлегенең Яңа Әхмәт яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган зат , I һәм II группа инвалидларыннан, ел дәвамында җирлек территориясендә яшәмәүче гражданнардан (студентлар; РФ Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче затлар, махсус хәрби операцияләрдә катнашучылар; хөкем ителгәннәр), тормышта авыр хәлдә калган гаилә әгъзалары (социаль куркыныч хәлдәге гаиләләр, янгыннан зыян күрүчеләрдән) тыш, 450 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) Яңа Әхмәт торак пунктында су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны тәэмин итүче инженерлык корылмалары төзү (су алу җайланмасы будкасы өчен төзелеш материаллары сатып алу);

2) Яңа Әхмәт торак пунктында һәйкәлне төзү, ремонтлау (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары түгел (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре)) һәм авыл клубы бинасы янындагы территорияне төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Сарман авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Сарман авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе (имза) Л.И. Шәрипова